Р Е С П У Б Л И К А
Т А Т А Р С Т А Н

И С П О Л Н И Т Е Л Ь Н Ы Й
К О М И Т Е Т  М И Ч А Н С К О Г О
С Е Л Ь С К О Г О  П О С Е Л Е Н И Я
С А Б И Н С К О Г О
М У Н И Ц И П А Л Ь Н О Г О
Р А Й О Н А
422055, Республика Татарстан, Сабинский район,
Село Старый Мичан , ул. Школьная , 12
тел. (84362) 42-3-31

Т А Т А Р С Т А Н
Р Е С П У Б Л И К А С Ы

С А Б А  М У Н И Ц И П А Л Ь
Р А Й О Н Ы  М И Ч Э Н  А В Ы Л
Җ И Р Л Е Г Е  Б А Ш К А Р М А
К О М И Т Е Т Ы

422055, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Иске Мичэн авылы., Мэктэп  урамы, 12 йорт
тел. (84362) 42-3-31

e-mail: mich.sab@tatar.ru

27.02.2019 № 3

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибен раслау хакында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 — ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясы һәм Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Уставы нигезендә Мичән авыл җирлеге башкарма комитеты карар итте:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләү буенча факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибен расларга. (1 нче  кушымта ).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/michan бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге башлыгы А.Ә.Гәрәевка йөкләргә.

Мичән авыл җирлеге башлыгы: А.Ә.Гәрәев

.

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Башкарма комитетының.2019 № карарына кушымта №1

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәтләре өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару Тәртибе.

I. Гомуми нигезләмәләр.

1.1 «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мичән авыл җирлеге Уставы нигезендә эшләнгән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләү чыгымнарының факттагы күрсәткечләрен бастырып чыгару тәртибе (алга таба — Тәртип)

1.2. Тәртип Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен белешмәләр тапшыру, раслау һәм рәсми бастырып чыгару процедурасын билгели (алга таба — мәгълүматлар).

II. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында мәгълүмат тапшыру тәртибе һәм составы.

2.1. Мәгълүматлар квартал саен җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең уртача саны, шул исәптән хисап чорында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашырган Мичән авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең исемлек буенча уртача саны турында, шулай ук хисап чорында хезмәт хакына исәпләнгән түләүләрне (акчалата эчтәлек) исәпкә алмыйча, хезмәт өчен түләү чыгымнарын тормышка ашыруга юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләре күләмен чагылдыралар.

2.2. Мәгълүматлар хисап чорыннан соң килүче айның 5 числосына кадәр әлеге Тәртипнең кушымтасы нигезендә бирелә.

2.3 Мичән авыл җирлеге башкарма комитеты әлеге Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма нигезендә мәгълүмат формалаштыра.

III. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибе.

3.1. Мичән авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан отчет чорыннан соң килүче айның соңгы числосыннан да соңга калмыйча, мәгълүматларны раслау турында Мичән авыл җирлеге башкарма комитеты карар проекты әзерләнә.

3.1.Мичән авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган белешмәләр квартал саен хисап артыннан килүче икенче айның соңгы числосына кадәр Мичән авыл җирлеге сайтында бастырылырга тиеш.

Мичән авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәтләре өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибенә кушымта

____________20___ел хисап чорына (беренче квартал, ярты ел, тугыз ай, ел))
Мичән авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында мәгълүматлар

| Хезмәткәрләр категориясе | хисап чоры өчен, хезмәткәрләр саны | хисап чорына хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнар. (Мең сумнарда) |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге муниципаль берәмлеге хезмәткәрләре | | |
| шул исәптән: муниципаль хезмәткәрләр | | |